КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативлары (иң чик саны) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлы исемендә «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы өчен» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы өчен» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «16. | «Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | | 1 | автобус | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | җиңел автомобиль | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | йөк автомобиле | 17 010 | 70»; |

18 нче һәм 19 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «18. | «Буа дәүләт драма театры» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | | 1 | автобус | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | җиңел автомобиль | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | йөк автомобиле | 17 010 | 70 |
| 19. | «А.В.Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры» дәүләт автоном учреждениесе | | 1 | автобус | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | микроавтобус/фургон | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | җиңел автомобиль | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | йөк автомобиле | 17 010 | 70»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | «Ашыгыч чакырулар хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе | | 2 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

12 нче һәм 13 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «12. | «Республика балалар-яшүсмерләр спорт-адаптив мәктәбе» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| 13. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының балаларга өстәмә белем бирүче «Динамо» республика махсуслаштырылган балалар-үсмерләр олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе | | 1 | җиңел автомобиль | 17 010 | 70 |
| | | | 2 | микроавтобус/фургон | 26 730 | 110 |
| | | | 1 | автобус | 17 010 | 70»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. | «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе | | 59 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135 |
| | | | 40 | җиңел автомобиль | 72 900 | 300 |
| | | | 7 | микроавтобус/фургон | 48 600 | 200 |
| | | | 16 | микроавтобус/фургон | 72 900 | 300 |
| | | | 14 | йөк автомобиле | 36 450 | 150 |
| | | | 420 | юлларда видеокүзәтү өчен җайланмалар урнаштыру, аларны саклау һәм тикшерүдә тоту өчен эш урынындагы максатларда файдаланыла торган шәхси җиңел автомобиль»; | | |

«Барлыгы» юлында «603» санын «606» санына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә:

«Искәрмә. «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе өчен өстәмә 44 махсуслаштырылган транспорт (автоэвакуатор) кулланырга рөхсәт ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин